**Принято**
На педагогическом совете
МАДОУ «Детский сад 366»
Протокол № 1 от 28.08.2023
Председатель________Э. И. Зайдуллина

**Утверждено**
Заведующий
МАДОУ «Детский сад 366»
Приказ № 45 от 28.08.2023
______________Э.И. Зайдуллина

# Рабочая программа

дополнительного образования

в МАДОУ «Детский сад № 366 комбинированного вида с

татарским языком воспитания и обучения»

кружка

«Татар теле – минем туган телем»

для детей подготовительной группы (6-7 лет)

Гизатуллина Гулина Шамилевна

педагог МАДОУ «Детский сад № 366»

Авиастроительного района г. Казани

Казань -2023

# “Татар теле – минем туган телем” түгәрәге

**Максаты**: балаларда туган телгә кызыксыну, ана телендә сөйләшәсе килү теләге уяту; татар телендә дөрес, матур, кимчелексез сөйләшү күнекмәләре бирү.

**Бурычлары:**

1.Балаларның сүзлек запасын баету һәм активлаштыру. Бәйләнешле сөйләмнәрен камилләштерү.

2.Туган телдәге барлык авазларның дөйрес әйтелешен үзләштерүләренә ирешү.

3.Мәгълүмати-аралашу технологияләрен файдаланып, аралашу сәләтләрен үстерү, аралашу культурасы формалаштыру.

4.Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү.

5.Татар халык авыз иҗаты аша туган телгә, туган халкына ихтирам, янәшә яшәүче милләтләргә хөрмәт, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү.

6.Туган телебезне ярату, зурлау, аңа соклану хисләре тәрбияләү.

**Билгеләнеше:**

Түгәрәкнең план-программасы мәктәпкә әзерлек төркеме өчен тәкъдим ителә.

Түгәрәк атнага бер тапкыр үткәрелә.

Түгәрәк эшенең дәвамлыгы 25 – 30 минут тәшкил итә.

# Аңлатма язуы

Балалар бакчаларының төп бурычы – балаларны кечкенәдән сәламәт, белемле, инсафлы, әдәпле һәм мәрхәмәтле итеп тәрбияләү.

“Татар теле – минем туган телем” түгәрәгендә балалар туган тел белән кызыксыналар, ана телендә сөйләшәсе килү теләге уяна, татар телендә дөрес, матур итеп ашыкмыйча сөйләшүгә өйрәнәләр. Без тәрбияләгән балалар үзенең халкын, милләтен ихтирамитсеннәр, аның байлыгын, тарихын сакласыннар иде. Дөньяга килгән һәр буын шул мөхитнең матурлыгын күрә, шулар ярдәмендә аның күңелендә туган телгә, туган җиргә мәхәббәт тернәкләнә башлый.

Алар бу шөгыльдә халкыбызның милли җәүһәрләре, язучыларының иҗаты белән танышалар. Табигатьне саклау мәсьәләрен өйрәнәләр. Патриотик тәрбия: туган ил, аны саклау турында да фикерләшәләр. Ул милләте, халкы белән горурланырга өйрәнәләр.

## Перспектив-тематик план

| Ат-на | Темасы | Бурычлары | Эш төрләре | Әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| **Октябрь ае** | | | | |
| 1 нче | **Ярат туган телеңне** | Татар теленең байлыгын, матурлыгын күрә белергә өйрәтү; туган телдә сөйләшү һәм аралашу теләге уяту. | 1.Әңгәмә үткәрү: “Туган телем – татар теле”.<br>2.Аудиоязмадан җыр тыңлау: Г.Тукай “Туган тел”.<br>3.Шигырь уку: Э.Мөэминова. “Туган телем”. | 1. “Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе” методик әсбабына аудиокушымта.<br>2. “Туган телдә сөйләшебез” китабы, 89 бит. |
| 2 нче | **Татар теле – минем туган телем** | Халкыбызның борныгы дан килгән бер-берсен сәдамләү сүзләре белән таныштыру; сүзләрнең аһәңле яңгырашын күрсәтү; **{ә}** авазының дөрес әйтелешен ныгыту. | 1.“Танышу” уенын уйнау.<br>2.Аудиоязма “ Әссәламегаләйкем!” җырын (Г.Садә сүзләре, Р.Ахъярова көе) тыңлау.<br>3.”Кем күбрәк сүз әйтә?” уенын уйнау. | 1. ”Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе” китабы,158 бит.<br>2.“Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы” китабы, 44 бит. |
| 3 нче | **Татар халкы-ның милли киемнә-ре** | Татар халкының милли киемнәре белән таныштыру; тасвирый хикәя төзергә өйрәтү; татар милли сәнгатенә мәхәббәт, ихтирам тәрбияләү. | 1.“Сынлы сәнгать музее” альбомын карау.<br>2. Р.Вәлиеваның “Энҗе-мәрҗән калфагым” шигырен уку.<br>3.Татар халкының “Яулык” уенын уйнау.<br>4.Тасвирый хикәя төзү. | 1.”Иң гүзәл тел – туган тел” китабы, 46 бит.<br>2.”Иң матур сүз” китабы, 240 бит. |
| 4 нче | **Ягымлы сүзләр** | *Рәхмәт*сүзенең килеп чыгышы белән таныштыру; ягымлы сүзләрне куллана белергә, үз-үзеңне матур тотарга өйрәтү; дуслык хисләре тәрбияләү; | 1. Ә.исхакның “Беренче рәхмәт” шигырен уку.<br>2.”Дуслар” җырын (Р.Корбан сүзләре, Ф.Әбүбәкеров көе) тыңлау.<br>3.Ә.Бикчәнтәеваның “Тәмле сүз” хикәясен уку, эчтәлеге | 1. “Иң матур сүз” китабы, 89 бит.<br>2.Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе: методик әсбап өйчен |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **{р}**авазының дөрес әйтелешен ныгыту. | буенча әңгәмә кору.<br><br>4.”Паровоз” уенын уйнау. | аудиокушымта.<br><br>3.”Туган телдә сөйләшәбез” китабы, 20 бит.<br><br>4.”Иң татлы тел – туган тел” китабы, 38 бит. |
| **Ноябрь ае** | | | | |
| 1 нче | **Арала-шу әдәбе** | Тормышта ягымлы сүздәрне еш кулланырга кирәклеген төшендерү; өйрәнгән сүзләрне кулланып, билгеле бер темага сөйләргә өйрәтү; сүзләрдә авазларны дөрес әйтергә күнектерү. | 1. Х. Халиковның “Якты сүз” шигырен уку.<br><br>2.”Тылсымлы сүзләр” уенын уйнау.<br><br>3.”Мәкаль әйтеш” (тел, ягымлы сүзләр турында) уенын уйнау.<br><br>4.”Чәчәк таҗлары” дидактик уенын уйнау. | 1. ”Балачак аланы” китабы, 363 бит.<br><br>2.”Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе” китабы, 66 бит. |
| 2 нче | **Кием кешене бизи** | Киемгә сакчыл караш, зәвык тәрбияләү,; матур итер киенергә теләк тудыру; сөйләм телләрен үстерү. | 1. “Кием кешене бизи” мәкаленең мәгънәсе буенча әңгәмә үткәрү.<br><br>2.Киемнәр кибетенә бару | “Иң гүзәл тел – туган тел” китабы, 46 бит. |
| 3 нче | **Әбием-нең санды-гы** | Милли киемнәрнең исемнәрен, бизәлешләрен сөйләмдә дөрес әйтүне активлаштыру; сәнгатьле сөйләмнәрен, логик фикерләү сәләтләрен үстерү; **{у},{ү}**авазларының дөрес әйтелешен ныгыту. | 1. “Үткәннәргә сәяхәт” слайдын карау.<br><br>2.”Серле сандык” уенын уйнау, милли киемнәр турында әңгәмә үткәрү.<br><br>3. Чагыштырма хикәя төзү.<br><br>4.”Түбәтәй” җырлы уенын уйнау. | 1.”Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе” китабы, 144-146 битләр.<br><br>2.”Иң аталы тел – туган тел” китабы, 14 -15 битләр. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4 нче | **Курчак-ны сый-лыйбыз** | Татар халык ашлары, ризыклары белән таныштыру; милли ризыкларыбыз *чәкчәк, өчпочмак*турында шигырьләр иҗат итү; тасвирлап сөйләү күнекмәләрен үстерү; **{ч}**авазының дөрес әйтелешен ныгыту. | 1. Ш.Галиевның “Кунаклар” шигырен уку.<br>2. “Алсу исемле курчак бездә кунакта” уенын уйнау.<br>3.”Кунаклар “ җырлы уенын уйнау.<br>4. Телшомарткыч өйрәнү: “Чыпчык, чыпчык, чык, чыпчык...” | 1. “Балачак аланы” китабы, 203 бит.<br>2.”Уйный- уйный үсәбез” китабы, 142 бит.<br>3.”Иң гүзәл тел – туган тел” китабы, 79 бит. |
| **Декабрь ае** | | | | |
| 1 нче | **Кунак булсаң, тыйнак бул** | Милли ризыкларыбыз белән таныштыруны дәвам итү; бәйләнешле сөйләм телләрен үстерү; шигырьнең мәгънәсенә төшенү; татар халык аваз иҗатына мәхәббәт тәрбияләү. | 1.Милли ризыклар турында слайдлар карау.<br>2.Р.Шарипованың “Өчпочмакмы, берпочмакмы?” шигыре буенча әңгәмә үткәрү.<br>3.Мәкаль өйрәнү. | 1.”Балачак аланы” китабы, 484 бит.<br>2.”Иң гүзәл тел – туган тел” китабы, 108 бит. |
| 2 нче | **Кунак каршы-лыйбыз** | Халкыбызның кунакчыллык, чисталык, тыйнаклык кебек күркәм сыйфатлары белән таныштыру; бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерүне дәвам итү; **{с}**,**{з}**авазларын дөрес әйтүне ныгыту. | 1. Р.Миннуллиның “Мин кунак яратам!” шигырен уку.<br>2. “Зилә, Самир кунакка килле” уенын уйнау.<br>3.Әңгәмә үткәрү: К.Насыйри. “Табын әдәпләре”.<br>4.”Винни Пух кунакта” дигән мультфильм карау. | 1.”Иң гүзәл тел – туган тел” китабы, 44 бит.<br>2.”Балачак аланы” китабы, 320 бит.<br>3.”Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы” китабы, 12 бит. |
| 3 | **Карга килде –** | Халак авыз тҗаты әсәрләре белән | 1.Бармак уены белән таныштыру. Катлаулы | 1.”Иң матур сүз” |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| нче | **казан асты...** | таныштыруны дәвам итү; игътибарлыкларын арттыру; хәтер сәләтләрен үстерү; **{ң}**авазының дөрес әйтелешен ныгыту. | сүзләрнең мәгънәсен ачыклау. Уенны яттан сөйләргә өйрәнү.<br>2.”Кайтаваз” уенын уйнау. | китабы, 365 бит.<br>2.”Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы” китабы, 23 бит. |
| 4 нче | **Табышмаклар илендә** | Халык авыз иҗатын кулланып, балаларның сүзлек байлыкларын, фикерәү, акыл сәләтләрен үстерү; **{з}** авазын дөрес әйтү әйтелешен ныгыту. | 1.”Табышмаклар илендә” дигән уен викторина үткәрү.<br>2.Такмалар әйтү.<br>3.Тел көрмәкләндергеч өйрәнү: “Без, без, безелдек, без бер рәткә тезелдек...” | “Иң матур сүз” китабы, 361 бит. |
| **Гыйнвар ае** | | | | |
| 3 нче | **Исемең матур – кемнәр куйган** | Һәр исемнең аерым бер мәгънә белдерүе турында төшенчә бирү; исем-фамилияләрне кыскартырга, үзгәртергә яисә бозарга ярамаганлыгын аңлату; **{к},{къ}**авазларын дөрес әйтүләрен ныгыту. | 1.Исем турында табышмак әйтү.<br>2.”Матур исем әйт” уенын уйнау.<br>3.”Мин кем?” уенын уйнау.<br>4.Мәкаль әйтү: “ Яхшы исем байлыктан да әйбәтрәк” .<br>Мәкальнең мәгънәсен аңлату. Ятлау.<br>5. **{к},{къ}** авазларын дөрес әйтү күнегүләрен эшләү. | 1.”Туган телдә сөйләшәбез” китабы, 52 бит.<br>2.” Иң татлы тел – туган тел” китабы, 65 бит. |
| 4 нче | **Туган телне зурлау, хөрмәт-ләү** | Халык иҗаты аша телебезнең байлыгын, матурлыгын күрсәтү; туган телебезне ярату, зурлау, аңа соклану хисләре тәрбияләү. | 1.Мәкаль әйтү: “Иң татлы тел - туган тел, әнкәм сөйләп торган тел”.<br>2.” Нигә авыз бер генә?” мәзәген сөйләү.<br>3.”Әссәламегаләйкем” җырын җырлау. | “Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе” китабы, 206-208 битләр. |

| Февраль ае | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 нче | **Мин бит татар егете** | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү; **{h},{х}** авазларын сүзләрдә дөрес әйтүне ныгыту; милләтең белән горурлану хисе тәрбияләү | 1.Р.Бәшәрнең “Мин бит татар егете” шигырен уку.<br>2.”Өйдәге вазифаларым” дигән әңгәмә үткәрү.<br>3. “Ха-ха, hи-hи” уенын уйнау. | 1.”Иң матур сүз” китабы, 6 бит.<br>2. “Иң гүзәл тел – туган тел” китабы, 65 бит. |
| 2 нче | **Батыр егет – ил күрке** | Ватанны саклаучылар турындагы кузаллауларын киңәйтү; кыю, батыр солдат булу теләге уяту; куркаклыкка тискәре мөнәсәбәт тәрбияләү. | 1.Кыюлык, батырлык турында әңгәмә үткәрү.<br>2.Үстерешле диалог: “Ватанны кемнәр саклый?”<br>3. К.Булатованың “Солдатлар” шигырен уку.<br>4. “Төлке, Куян һәм Әтәч” мультфильмын карау. | “Туган телдә сөйләшәбез” китабы, 90 бит. |
| 3 нче | **Ил сакчы-лары** | Ватанны саклаучылар турындагы белемнәрен ныгыту; герой-шагыйрь М.Җәлил иҗаты белән кызыксынуларын арттыру; сәнгатьле сөйләм сәләтләрен үстерү; **{ж}** авазын дөрес әйтүләрен ныгыту. | 1.Туган ил турында мәкальләр әйтү.<br>2.М.Җәлил турында әңгәмә үткәрү (слайдлар ярдәмендә)<br>3.Р.Корбанның "Җәлил турында җыр”ын тыңлау. | “Туган телдә сөйләшәбез” китабы, 234 бит |
| 4 нче | **Әни кирәк** | Бирелгән сүзләр белән хикәя төзергә өйрәтү; игътибарлыкны арттыру;**{ә}**авазының дөрес әйтелешен ныгыту; әти – әнигә хөрмәт тәрбияләү. | 1.”Әни кирәк” җырын (Р.Миннуллин сүзләре, М.Шәмсетдинова көе) тыңлау.<br>2.”Кемнең әнисе кайда эшли?” дидактик уенын уйнау. | 1. Иң гүзәл тел – туган тел” китабы, 102 бит.<br>2. “Туган телдә сөйләшәбез” китабы, 94 бит. |

| Март ае | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 нче | **Жыр-лыйм әнием турында** | Шигърият аша әниләргә мәхәббәт тәрбияләү; сәнгатьле сөйләм сәләтләрен үстерү. | Әниләргә (дәү әниләргә, апа-сеңелләргә) багышланган шигырь бәйрәме үткәрү. | "Иң матур сүз" китабы, 339-342 битләр. |
| 2 нче | **Китап – белем чишмәсе** | Китаплар белән кызыксыну, аларга сакчыл караш тәрбияләү; эзлекле фикерләү сәләтләрен үстерү, тел байлыкларын арттыру; **{ө},{о}**авазларының дөрес әйтелешен ныгыту. | 1.Әкият, такмак, шигырь һ.б. китаплар белән таныштыру.<br><br>2."Мин кайсы әкияттән?" уенын уйнау.<br><br>3. "Гөрләмеш" уенын уйнау | 1."Балалар бакчасындаж әдәп-әхлак тәрбиясе" китабы, 127 бит.<br><br>2. "Иң татлы тел – туган тел" китабы, 23 бит. |
| 3 нче | **Китап – белем чишмәсе** | Китапханә турында белемнәрен ныгыту; тасвирлап сөйләү күнекмәләрен үстерү; эзлекле фикерләү сәләтләрен ныгыту. | Китапханәгә экскурсия оештыру. | "Иң гүзәл тел – туган тел" китабы, 149 бит. |
| 4 нче | **Кызыл китап** | Сирәк очрый торган җәнлекләр, үсемлекләр турындагы китап белән таныштыру; мөстәкыйль фикерләү сәләтләрен үстерү; тасвирлап сөйләү күнекмәләрен ныгыту; **{р}**авазының дөрес әйтелешен ныгыту. | 1. "Өзелгән чәчәкләр" хикәясен уку. Эчтәлеге буенча әңгәмә үткәрү.<br><br>2. "Кызыл китап" турында сөйләү.<br><br>3. "Көнбагыштагы юлбарыс" мультфильмын карау.<br><br>4. "Цирк аренасында" уенын уйнау. | 1. "Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе" китабы, 203 бит.<br><br>2. "Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы" китабы, 24 бит. |
| **Апрель ае** | | | | |
| 1 нче | **Урман кагыйдә-ләре** | Урманның әһәмияте турында белемнәрен ныгыту; бәйләнешле сөйләмнәрен үстерү; **{у}**авазының дөрес әйтелешен ныгыту. | 1.Табышмак әйтү.<br><br>2.Урман кагыйдәләре турында әңгәмә үткәрү.<br><br>3. "Урман турында ниләр беләсең?" | 1. "Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе " китабы, 248 бит.<br><br>2. "Иң гүзәл тел – туган тел" |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | темасына балалардан сөйләтү.<br>4. “У кайда?” уенын уйнау. | китабы, 139 бит. |
| 2 нче | **Г.Тукай иҗаты** | Г.Тукай иҗаты белән кызыксынуларын арттыру; әдәби әсәрләрне тыңлый, эчтәлеген сөйли белүләренә ирешү; **{т}**авазын дөрес әйтүләрен ныгыту. | 1. Г.Тукайныэ “Кызыклы шәкерт” шигырен уку.<br>2. “Кайсы әсәрдән – бел” үстерешле уенын уйнау.<br>3. “Телефон” уенын уйнау. | 1.”Туган телдә сөйләшәбез” китабы, 119 бит.<br>2. “Иң гүзәл тел – туган тел” китабы, 98 бит. |
| 3 нче | **Шигърият дөньясында** | Шигърият белән кызыксыну тәрбияләү; логик фикерләү сәләтләрен үстерү; дөрес дикция белән һәм төрле темпта сөйләшә белергә күнектерү. | “ Без – Тукай оныклары” дигән әдәби викторина үткәрү. | “Туган телдә сөйләшәбез” китабы, 121 бит. |
| 4нче | **Сезгә тиеш әле бик күп назлар** | Бөек Ватан сугышы ветераннарының батырлыклары турындагы белемнәрен киңәйтү; патриотик хисләр, Туган илгә мәхәббәт тәрбияләү. | 1. “Хәтер” китабы белән танышу (слайдлар<br>2.”Җиңу көне” җырын (А.Гайнетдинова сузләре һәм көе) тыңлау.<br>3. “Солдат батырлыгы” темасына тасвирый хикәя төзү. | “Туган телдә сөйләшәбез” китабы, 278 бит. |
| **Май ае** | | | | |
| 1-2 нче | **Сезгә тиеш әле бик күп назлар (кабатлау)** | Ватанга мәхәббәт, патриотик хисләр, кыю һәм батыр булу теләге тәрбияләү. | 1.Җиңү көненә багышланган бәйрәм оештыру.<br>2.Бөек Ватан сугышы геройлары һәйкәленә чәчәкләр кую. | “Туган телдә сөйләшәбез” китабы, 279 бит. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| 3-4<br>нче | **Без яшибез дуслык илендә (кабатлау)** | Идел буе халыклары, аларның тормыш-көнкүреше, тел үзенчәлекләре һ.б. турындагы белемнәрен ныгыту; янәшә яшәүче милләтләргә хөрмәт, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. | “Без яшибез дуслык илендә” дигән бәйрәм кичәсе үткәрү. | “Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе” китабы, 408-413 битләр. |

Файдаланылган әдәбият:

1. Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе: методик әсбап өчен аудиокушымта / {төз. : Закирова К.В., Кадыйрова Р.Ә}. Казан. : “Аксу” компаниясе, 2003

2. Иң матур сүз китабы / {төз. : Закирова К.В. }. Казан.,2012

3. Туган телдә сөйләшәбез. 5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшүдә өйрәтү буенча методик ярдәмлек. Казан, 2012

4. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия / {төз. : Закирова К.В. }. Казан.,2011

5. Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы, {төз. : Шәехова Р.К. }. Казан.2011

6. Иң гүзәл тел – туган тел {төз. : Кашапова М.Ф. }. Казан.,2009